# ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Гремячий Ключ торак пунктында үткән гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

19 ноябрь 2023 ел №10

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә шушы сорау буенча 2023 елның 19 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2024 елда Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлегенең Гремячий Ключ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннарының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500,00 сум күләмендә түбәндәге эшләрне башкару буенча үзара салым кертергә риза буласызмы?

1. авыл җирлеге чикләрендә автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту, инерт материаллары сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлаштыру;
2. территориянең тышкы төзекләндерү объектларын төзү һәм ремонтлау (контейнер мәйданчыклары төзү), шул исәптән бу максатлар өчен төзелеш материаллары һәм контейнерлар сатып алу;
3. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру

«ӘЙЕ» « КАРШЫ»».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә **7** кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә **5** кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен җыенда **4** кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан **1** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Гремячий Ключ авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.
2. «2024 елда Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлегенең Гремячий Ключ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннарының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш,

500,00 сум күләмендә түбәндәге эшләрне башкару буенча үзара салым кертергә риза буласызмы?

1. авыл җирлеге чикләрендә автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту, инерт материаллары сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлаштыру;

2. территориянең тышкы төзекләндерү объектларын төзү һәм ремонтлау (контейнер мәйданчыклары төзү), шул исәптән бу максатлар өчен төзелеш материаллары һәм контейнерлар сатып алу;

3. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру» соравы буенча **карар кабул ителде.**

3. Әлеге карарны Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт ( авыл мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында http://zelenodolsk.tatarstan.ru интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зеленодольск муниципаль районы
Бишнә авыл җирлеге башлыгы: И. М. Фәтхуллин